МАОУ СОШ №4

# Наше Время!

# Безнең Вакыт!

ЯНВАРЬ



## Әти-әни балага якынаяя

Мәдәният елыннан Әдәбият елына күчкәндә, яңа проект старт алды. Аның нигезендә 12 ноябрьдә республиканың беренче сыйныф укучылары китапханәләргә килделәр. Ә бу, аз да түгел, күп тә түгел, 42 мең 238 нәни китап сөюче теркәләчәк дигән сүз.



## Безнең кунаклар

## Истәлекле даталар



## К 70 летию Победы!

## Истәлекле очрашулар

## Бөек Җиңү кайтавазы!



2015 ел Татарстанда Парклар һәм скверлар елы дип игълан ителде







**Факиль Миннемухаметович САФИН (Факиль Амак)**
**Факил Миңнемөхәммәт улы САФИН (Факил Әмәк)**
**прозаик, поэт, публицист**

**Родился 2 января 1954 года в селе Амак Муслюмовского района ТАССР. Член Союза писателей Татарстана.**
**В Набережных Челнах с 1984 года.**
**Работал на автомобильном заводе (1984-1988), после чего на редакторской работе в газетах «Таң йолдызы», «Көмеш кыңгырау», журналах «Аргамак», «Наука и школа», «Майдан», «Казан утлары». Некоторое время (2006) – заместитель председателя Союза писателей Татарстана. С 2006 года – заведующим отделом центра развития образования.**
**Главный редактор газеты “Көмеш кыңгырау”.**
**Автор книг «Соңгы көз» («Последняя осень», 1992), «Гөлжиһан» («Гульджихан», 1988), «Тузганак чәчәге» («Одуванчик», 1994), «Биек тауның башларында» («На вершине высоких гор», 1998), “Җыр—гомер ул” (“Песня—это жизнь” 2014), “Былбыл оясы” (“Гнездо соловья» 2014).**
**Награждён медалью «В память 1000-летия Казани», заслуженный работник культуры Татарстана», лауреат премии имени Гаяза Исхаки., Александра Грибоедова, обладатель международных дипломов «Олимп перевода» и «За солнечное творчество»**
**Указом Президента РТ Факиль Сафин награжден медалью «За доблестный труд» 2014 году.**

**Факил Сафин Мөслим районының Әмәкәй авылында 1954 елның 2 гыйнварында туа. Күбәк урта мәктәбен тәмамлагач, колхозда механизатор булып эшли. Минзәләдә машина йөртүчеләр курсын тәмамлый. 1972-1974 елларда Совет армиясе сафларында хезмәт итә. Ерак Көнчыгыш, Кытай чигендә хезмәт иткәндә дә әдәбият өлкәсендә иҗади эшчәнлеген туктатмый. Армиядән кайту белән, районның иң зур хуҗалыгы – “Михайловка”га комсомол оешмасы секретаре итеп, соңыннан Иске Карамалы мәдәният йортына директор итеп билгеләнә. Казан дәүләт университетының тарих-филология факультетын тәмамлый. Педагогик эшчәнлеген Ф.Сафин Октябрь авылында башлый. Өйләнгәч туган авылына кайта, монда әдәбият, тарих һәм башлангыч хәрби әзерлек дәресләрен укыта башлый. 1981 елда Октябрь мәктәбенең укытучылар үтенече белән әлеге мәктәпкә директор итеп билгеләнә. 1984 елда язмыш аны Чаллы шәһәренә китерә. Ул КамАЗ автомобиль заводына слесарь булып эшкә урнаша – башта конвейерда җыючы, аннары бригадир, мастер итеп билгеләнә. Эшләү дәверендә 1 класслы мастер дәрәҗәсенә күтәрелә, “КамАЗ”ның мактау тактасына исеме кертелә. 1988 елда Автозаводның мәгариф бүлеге аны педагогик эшкә чакыра. Ул 24 нче һәм 18 нче мәктәпләрдә тарих фәне укыта. Шәһәр тарихында беренче тапкыр рус телле балаларга “Татар халкының тарихы, әдәбияты, мәдәнияте” фәне керә башлый. Тиздән аны Тукай районы мәгариф бүлегенә күчерәләр. Аның исеме шәһәр матбугатында күренә башлый. 1990 елда «Таң йолдызы» газетасында баш редактор урынбасары булып эшли. 1991 елның февралендә “КамАЗ” радиосының татарча программалар редакциясенә күчә. 1991 елның августында, журналист һәм шагыйрь, милли хәрәкәтнең актив катнашучысы булган Факил Сафин, “Аргамак” журналының проза һәм поэзия бүлегенә редактор итеп чакырыла. Аның беренче санын чыгаруда һәм журналны саклап калуга зур көч куя. 1995 елның сентябрь аеннан шәһәр идарәсе тәкъдиме белән Чаллы педагогик колледжына әдәбият фәнен укытырга бара. Студентларның хөрмәтен һәм яратуын яулый. Яңалыкка омтылу, яңа технологияләрнең һәм укыту-тәрбия эшендә яңа төр методиклар барлыкка килү шәһәр җитәкчеләрен яңа фәнни-методик журнал ачуга этәрә. Бу эш нәкъ менә Факилгә йөкләнә. Аның кул астында 1996 елның октябреннән “Фән һәм мәктәп” журналы чыга башлый. Әдәбиятка ул бай тормыш тәҗрибәсе белән килә. Аның “Соңгы көз”, “Гөлҗиһан” повестьлары, “Биек тауның башларында” романы, “Саташып аткан таң” трилогиясе, күп сандагы хикәяләре, Кадыйр Сибгатуллин, Рәшит Бәшәр, Зөлфәт, Мөдәррис Әгъләмов һ.б. язучылар, шагыйрьләр турында язылган фәнни-тикшеренү, критик язмалары, публицистик мәкаләләре, шигырьләре, эпиграммалары, пародияләре дөнья күрә. 2000 елның көзендә Казанга «Казан утлары» журналы редакторы итеп чакырыла. Ләкин 2001 елда шәһәр администрациясе һәм язучылар берлеге җитәкчеләре Чаллы шәһәрендә яңа әдәби-нәфис журнал чыгару эшен Ф.Сафинга йөклиләр. Кыска гына вакыт эчендә «Мәйдан. Чаллы» исемле әдәби-нәфис журнал оештырыла. “Җыен” фонды белән үзешчән композиторлар арасында үткән балалар җырлары конкурсында лауреат исемен ала. “Тургай” җыр фестивалендә оештыруда да катнаша ул һәм беренче урынны ала. Ул шулай ук балалар иҗаты түгәрәген оештыручыларның берсе булып та тора. Балалар иҗаты йортында җитәкче булып эшләү дәверендә ул “Көмеш кыңгырау” газетасын хасил итүдә катнаша. Ф.Сафин – Татарстанның атказанган мәдәният работнигы (2004). Татарстан Язучылар берлегенең Г. Исхакый исемендәге әдәби премиясе белән бүләкләнә (1999), 1996 елдан – Татарстан Язучылар берлеге әгъзасы. 2015 ел—Яр Чаллы Язучылар берлеге рәисе.**

Шагыйрь Галиәхмәт Шаһи ( Галиәхмәт Шаһиәхмәт улы Шаһиәхмәтов) 1949 елның 24 августында Татарстанның Арча районы Шура авылында туа. Үз авылларында сигезьеллык мәктәпне тәмамлагач, бәхет эзләп, мари якларына барып чыга. Йошкар-Ола шәһәрендә техникумда укый. Техникумны технолог белгечлеге буенча диплом алып тәмамлагач, шактый еллар сәүдә системасында һәм Уфа, Оренбург, Ташкент, Алма-Ата шәһәрләрендәге төрле хуҗалык оешмаларында эшли, комсомол путевкасы белән дүрт елга якын Оренбург өлкәсендәге Иракла (Ирекле) ГРЭСы төзелешенә хезмәт көчен куя. Узган гасырның җитмешенче еллары ахырында ул янә туган якларында: Арча район газетасы редакциясенә әдәби хезмәткәр булып эшкә урнаша, бер үк вакытта читтән торып Казан дәүләт университетының журналистика бүлегендә укый. Шул елларда аның үзе эшләгән район газетасы битләрендә беренче шигырьләре басыла.

1984 елдан ул – Чаллы шәһәрендә, биш ел шәһәр мәктәпләрендә укытучылык һөнәрен дәвам иттерә. Аннары, сәламәтлеге начараю сәбәпле, укыту эшен ташлап, үзенең бөтен рухи көч-сәләтен гомере буе хыялында йөрткән әдәби иҗат эшенә, шигърияткә багышлый. 1997 елда Чаллы шәһәр матбагасында аның «Кояшлы юл» дигән беренче шигъри җыентыгы басылып чыга.

Г.Шаһи – 2004 елдан Татарстан Язучылар берлеге әгъзасы.





НАШЕ ВРЕМЯ! БЕЗНЕҢ ВАКЫТ!

**Галиахмет Маратович ШАГИАХМЕТОВ**
**Родился 24 августа 1949 года в деревне Шура Арского района ТАССР.**

**В Набережные Челны прибыл в 1983 году из Азнакаево.**
**Работал преподавателем татарского языка в средних школах №10 и №12.**
**Член Союза писателей Татарстана.**
**Автор книг «Кояшлы юл» («Солнечный путь», 1997), «» («Река любви», 1998), «Ай ташы» («Ледяной камень», 2001), «Канатлы еллар» («Крылатые годы», 2002), «» («Нагляжусь вдосталь», 2006) и других.**





**Галиәхмәт Шаһи (Автор песен)**

## ТӨП БАСМА КИТАПЛАРЫ

**Кояшлы юл: шигырьләр. – Чаллы: Шәһәр матбагасы, 1997.**
**Мәхәббәт елгасы: шигырьләр. – Чаллы: Шәһәр матбагасы.**
**Кулым җылысы: шигырьләр. – Чаллы: КамАЗ, 2001. – 64 б. –**
**Моңлы китап: шигырьләр. – Чаллы: Шәһәр матбагасы, 2001.**
**Ай ташы: шигырьләр. – Чаллы: КамАЗ, 2002. – 32 б. – 700 д.**
**Әүлия чишмәсе: шигырьләр. – Чаллы: Шәһәр матбагасы,**
**Канатлы еллар: шигырьләр. – Чаллы: КамАЗ, 2003. – 128 б.**
**Сандугач кайткан таллыкка: шигырьләр. – Чаллы.**



# Рашит Гафарович БАШАРОВ (Рашит Башар)
# Рәшит Гафар улы БӘШӘРОВ (Рәшит Бәшәр)
## Поэт, прозаик

**Родился 7 октября 1949 года в деревне Янил Кукморского района Татарстана.**

**Член Союза писателей Республики Татарстан.**

**В Набережные Челны переехал в 1979 году из Лениногорска.**

**Работал: на Прессово-рамном заводе (1974-1984), заводе запасных частей (1984-1987), заведующим отделом газеты «Таң йолдызы» (1989-1991), редактором издательства «КамАЗ» (1991-1995), редактором журнала «Аргамак» (1995-2000), редактором газеты «Майдан» (2001 – н.в.).**


**- Автор книг: «Әйлән-бәйлән» («Хоровод», 1975), «Бәйрәм» («Праздник», 1977), «Яшел океан» («Зелёный океан», 1981), «Ак әкият» («Белая сказка», 1986), «Ачык капка» («Раскрытые ворота», 2004), «Җәй кызы» («Девочка лета», 2007) и другие.**

**- Награждён: медалью «В память 1000-летия Казани», знаком «За вклад в культуру» (2005), удостоен литературных премий имени Эдуарда Касимова (1989), Сагиды Сулеймановой (1997), Абдуллы Алиша (2000).**








**Әсәрләре 1965 тән басыла башлый. Балаларга атап язылган, аларны кечкенәдән үк намуслы, кешелекле, ихлас булырга, хезмәтне яратырга, табигатьне сакларга, аны баетырга, терек-лек дөньясы белән дус булырга чакырган «Әйлән-бәйлән» (1975), «Бәйрәм» (1977), «Яшел океан» (1981), «Җиләк малай» (Чаллы, 2002), «Кояшлы яңгыр» (2003) исемле шигырь җыентыклары, Себер табигатенең хозурлыгы турындагы «Ак әкият» (1986), әкият-легендаларда сөйләнгән Зөһрә кыз турын-дагы «Ай кызының зәңгәр чиләге» (1990) исемле поэма китап-лары авторы. «Иртәгә дә яшисе бар» (1989), «Ачык капка» (2004) җыентыкларына тупланган повестьларында Бәшәр яшүсмерләрне тәрбияләү проблемаларын яктырта; кайвакыт тормышта чын дөреслек булып күренгәннең дә ялган булып чыгуын фаш итә.**

МАОУ "СОШ №4"



# К 70 летию Победы!




**На каникулах мы посетили МУЗЕЙ БОЕВОЙ СЛАВЫ города Набережные Челны. Посещение этого музея оставило в моей душе незабываемые ощущения. В музее находятся вещи пропавших без вести солдат. Каждая вещь в музее имеет свою историю. Группа поисковиков из Челнов находят пропавших солдат, поднимают останки из-под земли и хоронят их по-человечески, успокаивая души погибших. В музее можно надеть солдатскую форму и сфотографироваться с различными видами оружия. Это был мой первый музей, в котором мне разрешили прикоснуться ко всему. Ещё в музее есть стена молодых солдат из Челнов, которые не вернулись после Чеченской и Афганской войны. Они погибли на войне, но не умерли в наших сердцах. Эти ребята остались героями, которые дали жизнь новому поколению. Мне очень понравился этот музей! Я хочу, чтобы все учащиеся нашей школы посетили этот музей и оставили в себе незабываемые воспоминания.**

**Горохов Эдуард Максимович**
**ученик 8А класса школы №4**








# К 70 летию Победы!

**Уку елының өченче чиреге. 4Б сыйныфы өчен шатлыклы вакыйга белән башланды. Балалар янына кунак булып Хезмәт ветераны, ЗЯБ бистәсенең ветераннар советы рәисе Сәрия Хаматовна килде.**

**Яңа ел, кышкы каникуллар тәэсиреннән арынмаган балалар кунак апага шигырьләр сөйләделәр, күмәкләп җырладылар, аңа матур теләкләр теләделәр. Сәрия Хаматовна бала чагында Яңа ел бәйрәмнәренең ничек узганын сөйләде, укучыларга үзенең изге теләкләрен җиткерде. Мөләем елмаюы, тәэсирле сөйләме белән балаларның йөрәкләренә үтеп керә алган апаны балалр бик яраттылар, киләчәктә тагын да шундый очрашулар булуын сорап, җылы күңел белән озатып калдылар.**

МАОУ "СОШ №4"

# Голоса войны

ИНТЕРНЕТ-СОБРАНИЕ ВОЕННЫХ ВОСПОМИНАНИЙ «Я ПОМНЮ» КАК РЕСУРС ДЛЯ ШКОЛЬНОЙ БИБЛИОТЕКИ

***В мае исполнится 70 лет, как окончилась Великая Отечественная война. Для сегодняшних школьников память о ней – наследие уже прадедушек и прабабушек. Даже старшеклассники, родившиеся в конце прошлого века, ряд ли застали в живых своих родных – солдат той войны. Они знают о ней только из книг и фильмов. Прямые, личные свидетельства им чаще всего недоступны. Но, к счастью, существует замечательный Интернет-проект «Я помню», http://iremember.ru/, который может помочь библиотекарю и учителю познакомить школьников с воспоминаниями и рассказами ветеранов, с неподцензурной версией войны «от первого лица».***

**Сегодня в базе «Я помню» тысячи интервью, собранных волонтёрами. Тексты подразделены по родам войск, существует рубрикация по годам войны, сражениям и операциям. Функционал сайта позволяет найти людей, воевавших в одно время в одном месте, посмотреть, как они описывают одни и те же события.**

**Собственно, помимо событий войны, сайт даёт прекрасную возможность показать школьникам, что такое память.**

**НАШЕ ВРЕМЯ! БЕЗНЕҢ ВАКЫТ!** Главный редактор—Власова М.Д. корреспонденты газеты:Салихова Л., Гарипов А.